# *Бәхилләшү*

*Бәзәкә авылы үзенең улын югалтты.Авылыбызда 32 елга якын колхоз рәисе булып эшләгән Ибраһим Миндар улы вафат. Бу хәбәрне ишетү бик авыр булды:күңел ышанмый, йөрәк кабул итә алмый, Аяз көнне яшен сугу менә шулай була торгандыр. Зур хәсрәт, авыр кайгыдан авыл боегып, сүрелеп калды кебек...*

Ибраһим Галимов 1983 елның июнендә Бәзәкә авылында колхоз рәисе итеп билгеләнде. Шул көннән башлап, ул белемен, көч-энергиясен, тырышлыгын “Кама” колхозын күтәрүгә, аны һәрчак алдынгы, мактаулы итү максатына багышлады. Бик тиздән ул моңа иреште дә: искиткеч осталыгы, сәләте, батырлыгы, бетмәс-төкәнмәс ихтыяр көче белән авылыбызны яңартты, кешеләрен үз итте, алар белән уртак тел тапты, яшьләрне үз тирәсенә туплап, җиң сызганып җитәкчелек эшенә кереште. Аңа ул вакытта 28 яшь иде.

Ибраһим Миндар улы җитәкче булып эшләгән дәвердә авылыбыз зурайды, матурайды. Яңа балалар бакчасы, ике катлы колхоз идарәсе, стадион, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга күркәм обелиск, ферма биналары төзелде. Сабантуй үткәрү өчен уңайлы урын булдырылып, тирәсенә каеннар утыртылды (милли бәйрәмебезне ул үзе оештырды, бар төр ярышларны гадел бәяләде).

Ә мәчет төзүдә Миннәхмәт ага Мөхәммәтдинов белән бергә янып-көеп йөрде ул.Төзелеш өчен колхоздан төз, юан бүрәнәләр бирде. Көн саен эш барышы белән танышып торды, кирәкле материалны алып кайтырга техника бирде. Нәтиҗәдә, 1989 елда, авылдашлар өчен мәчетебез ишекләрен ачты, авыл өстендә азан тавышы яңгырады. Шул көннән башлап, хуҗа кеше үзе дә, вакыты булган саен, җомга намазларын калдырмады. Кечкенәдән ике улын үзе белән мәчеткә йөртте. Гомумән, Ибраһим Миндар улы динебезне хөрмәтләүче, аның кануннары буенча яшәүче зат иде. Берничә ел рәттән ул мәктәп ашханәсендә авыл халкы өчен ифтар ашлары, ә Корбан гаетендә чалу өчен симертелгән маллар биреп, шулай ук зур мәҗлесләр үткәрде.

Ибраһим Галимов балалар яратты. Вакыты бик тыгыз булса да , ул балалар бакчасында, мәктәптә үткәрелгән бер генә бәйрәмне дә калдырмады. Укучыларның төрле иҗади бәйге, фән олимпиадаларында ирешкән уңышларына сөенде, җиңүчеләргә шәхси премияләр тапшырды. Авыл яшьләре белән дә тыгыз элемтәдә яшәде, һәр чараның иганәчесе булды. Авыл клубының һәрчак гөрләп торуын теләде.Үзе бик җиңел, оста бии иде, бәйрәмдә биемичә калмады, чөнки халык аны үзе чакырды. 5 ел рәттән Казаннан режиссёр чакыртып, Бәзәкә сәхнәсендә генә түгел, күрше авылларда һәм районда спектакльләр куюны оештырды, үзе дә теләп уйнады. Катнашучыларны зурлап бүләкләде.

Ә спорт өчен Ибраһим Галимов җанын бирергә әзер кеше булды. Яшьләр белән рәхәтләнеп волейбол уйнады, чаңгыда йөрде, күп ярышларның судьясы булды. Мәктәпнең кызлар командасы аның әйдәп баруы белән берничә ел рәттән районда волейбол ярышларында беренчелекне бирмәде. Кызлар, мәктәпне тәмамлап, таралышкач та , җәй айларында аларны һаман ярышларга җыйнады.

Спорт фанаты буларак , 2014 елда Сочида үткәрелгән кышкы олимпиадага ул кызы белән “җанатар” булып барды. Бу уеннарны өйдә, диванда утырып кына карый ала

иде ул. Аңа ярышларның нәкъ үзәгендә булу, үз күзе белән күрү, һәр күзәнәге белән тою зарур иде.
Уйлап карасаң, колхоз рәисенең бу гамәлләрдән тыш, төп вазифасы да аз түгел.
Кырчылык, терлекчелек тармагында бихисап эшләре җәйрәп ята, борчу-мәшәкатьләре дә баштан ашкан иде. Ул көнозын кыр-басуларда булды. Озаклап яуган яки бер тамчы да төшмәгән яңгырлар өчен борчылды, янды-көйде, үз-үзенә урын таба алмады. Терлекчелектә туып торган проблемаларга үртәлде, белгечләр белән берлектә эшне җайга салу юлларын эзләде. Ничек кенә булмасын, хуҗалык хезмәтчәннәре, авырлыкларны җиңеп, чәчәсен чәчтеләр, җыясын җыйдылар, терлекчелектә дә югары уңышларга ирештеләр. Юкка түгел, һәр елны район Сабантуенда “Кама” колхозы” вәкилләре бәйрәм флагын күтәрүче һәм кыр батырлары парадының алгы сафында баручылар булды. Болар барысы да хуҗалык җитәкчесенең алга куйган максатларны дөрес, төгәл итеп, үз вакытында, сыйфатлы һәм намус белән башкару нәтиҗәләре. Ибраһим Галимов озак еллар район Советы депутаты, районда лидер, әйдәп баручы җитәкче булды. Ул масая, мактана белмәде, дан-шөһрәт артыннан кумады. “Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре” дигән исем дә аңа 2014 елда гына бирелде.
Санап киткән эш-гамәлләр рәис Ибраһим Галимов башкарганның меңнән бере генә.
Болардан тыш җитәкченең зур һәм җитди вазифасы – кадрлар белән эшләү, авыл кешеләре белән дөрес һәм якын мөгамәләдә булу. Монысын инде институтларда өйрәтмиләр. Бусы – синең йөрәгең , намусың эше. Тормышта бит адәм баласына һәрчак нидер җитми, һаман нәрсә дә булса кирәк. “Бир, кирәк!- дип сораган бер кешегә: “Мә, ал”, -дип әйтеп тә булмый торгандыр. Шунлыктан, фикер каршылыклары, ризасызлык килеп чыкканда, кычкырышкан, кызып киткән чаклар да байтак булды! Әмма рәис Галимов ачу тотмады, үч алмады, теге яки бу гаепләре өчен авылдашларны суд юлларында йөртмәде, эшне югарыга җибәрмәде. Менә шул сыйфатлары белән ул 32 ел дәвамында колхозны таркатмады, авылны бетермәде. Чиксез рәхмәттән башка ни әйтәсең аңа. Ибраһим Миндар улы тормышның ямен белеп яшәде, яшен булып яшьнәде, җәйге аҗаган булып авылыбыз күген яктыртты. Ә йөрәк түзмәде, туктап калды...
Хуҗалыгыбыз рәисен соңгы юлга озатырга бөтен авыл җыйналды. Мәрхүм исеменә рәхмәт һәм хөрмәт, үкенеч тулы хушлашу сүзләре әйтелде. Җәсәден туган ягы Чирмешәнгә алып чыгып киткәндә, яңгыр ява башлады. Әйтерсең, табигать тә аны югалту ачысыннан елый иде...
Мәрхүм гаиләсенең кайгысын уртаклашабыз, күркәм сабырлык телибез. 33 ел буена иңне-иңгә куеп , һәр башлангычында ярдәм иткән хатыны Сәрия ханымга Ходай түземлек бирсен. Ибраһим Миндар улының рухы шат, урыны җәннәтләрдә булсын. Аның якты истәлеге бәзәкәлеләр күңелендә бик озак сакланыр. Хәер, колхоз идарәсе каршында Ибраһим Галимов үз куллары белән утырткан мәһабәт зәңгәрсу чыршылар олы хөрмәткә лаек шәхесне онытырга ирек бирмәсләр.
P.S Мбраһим Галимов төзеткән , үзе озак еллар эшләгән бинага аның барельефын куярга тәкъдим итәм.

Бәзәкә халкы исеменнән педагогик хезмәт ветераны Рәмзия Мөхетдинова
“Менделеевск яңалыклары” 20 март 2015 ел